# Татар телендә сүзләрнең морфемик төзелешендәге кайбер үзенчәлекләр

Ч.М.Харисова, редколлегия әгъзасы
Ч.С.Мозаффарова, КФУ студенты

Татар телендә сүзләр морфемик төзелеше ягыннан тамыр, нигез һәм кушымчадан тора. Аларның һәрберсендә аерым үзенчәлекләр күзәтелә.

Тамыр морфема сүзнең төп (лексик) мәгънәсен белдерә, аерым сүз төркеменә керә, телдә сөйләм берәмлеге буларак аерым да кулланыла ала һәм тамырдаш сүзләр ясауда катнаша: *сүз-лек, сүз-чән, сүз-чән-лек, сүз-ле, сүз-сез, сүз-сез-лек* һ.б.

Телебездәге сүзләрнең нигезе аның төп мәгънәсен саклый (В.Н.Хангилдин); тел һәм сөйләм берәмлеге буларак кулланыла: *үзгәреш-ләр;* сүз ясауда катнашкан кисәкләрдән ягъни тамыры белән ясагыч кушымчалардан тора: *каенлык-та.*

Билгеле булганча, сүзнең нигезе тамыр һәм ясалма булырга мөмкин. Тамыр нигезле сүздә әлеге ике морфема ягъни тамыры белән нигезе бердәй була һәм ясагыч кушымчалар булмый: *кайт-ты.*

Ясалма нигезле сүздә, гадәттә, кайсыдыр ысулда кулланыла торган ясагыч элементлар була. Татар телендә түбәндәге очракларны ясалма нигезле сүзләр дип карарга мөмкин:

1) бер яки берничә ясагыч кушчасы булган сүзләр: *кеше-лек, кеше-лек-ле, кеше-лек-ле-лек*.

2) ике яки берничә тамырдан ясалган сүзләр: *бала-чага, көнчыгыш, Киек каз юлы;*

3) сүзләр кыскару ысулы белән ясалган сүзләр (аббревиатуралар): *КФУ, БДИ, Таттелеком*;

4) бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү ягъни конверсия ысулы белән ясалган сүзләр: *Апам – укытучы* (исем).

Татар телендәге фигыльләрнең нигезе формасы ягыннан телебездәге боерык фигыльләр белән аваздаш була. Чагыштырыгыз: *кил-де, җырла-ды.* Шуңа күрә теләсә кайсы фигыльнең нигез өлешенә боерык фигыль дип әйтү дөреслеккә туры килми, әлеге мисалларда хикәя фигыльләрнең нигезе билгеләнде, ә боерык фигыль – ул аерым мәгънәгә (ешрак боеру мәгънәсенә) ия булган һәм аерым интонация (ешрак боеру интонациясе) белән әйтелә торган төркемчә.

Телебезнең төп категориаль үзенчәлеге аның ялганмалы табигатендә чагылыш таба, ягъни ул агглютинатив телләрдән санала. Гадәттә, сүзнең тамырына яки нигезенә бер грамматик мәгънәгә ия булган кушымча ялгана: *сүз-ләр* – предметның бердән күп (берничә) булуын күрсәтә торган күплек сан кушымчасы белән кулланылган. Бер кушымчада ике грамматик мәгънә булу фигыльләрнең зат-сан күрсәткечләрендә ачык күренә: *бара-м* – эш-хәрәкәтне берлек сандагы I зат үти; *бара-сың* - эш-хәрәкәтне берлек сандагы II зат үти һ.б. Моннан тыш зат-сан өчен аерым кушымчалар боерык фигыльләрдә күзәтелә: *бар-сын-нар.* Күпчелек кушымчалар үзләренең аваз составын үзгәртмичә кулланылулары белән аерылып тора. Кушымча чикләрендә сузык авазлар очрашканда, аларның берсе кыскарырга мөмкин: *бар-м(а)-ый – бармый.* Морфема чикләрендә ике аваз кушылмасын белдергән хәрефләр булганда, аларны авазларга таркатырга туры килә, чөнки сүз төзелешен тикшерү һәм аның морфема чикләрен төгәлрәк билгеләү дә шуңа бәйле була: *елмаялар* - *елма(й+а)-лар.* Сузык аваздан башланган кушымча ялганганда, тамыр яки нигез ахырында килгән саңгырау тартык яңгырау пары белән чиратлаша: *мәктә(п)б-е.*

Татар телендәге кушымаларның сүзләргә ялгануы андагы төп закон – сингармонизмга бәйле. Бу законга “буйсынган” сүзләрдә алар я калын (*урманнарыбызда*), я нечкә (*көндәлекләрегезнең*) булырга мөмкин.

Сингармонизм күзәтелмәгән сүзләрдә кушымчалар, гадәттә, аның ахыргы иҗегенә карап ялгана: *китап-ка, көнчыгыш-та.* Нечкәлек билгесенә беткән рус алынмаларында исә тартым кушымчасы нечкә, килеш кушымчасы калын була: *календар-е-на*.

Телдәге кушымчаларның бик күп төрле булуы аларны билгеләүдә кайбер кыенлыклар да китереп чыгарырга мөмкин. Кушымчаларның төрен функциональ яктан чыгып билгеләгәндә, безнең уебызча, аларны өйрәнү һәм өйрәтү җиңелрәк булыр иде. Бу җәһәттән кайберләренең яңа лексик берәмлекләр ясавын яки сүзнең төп мәгънәсенә өстәмә төгәллек кертүен истә тотып, күп санлы кушымчалар ясагычлар дип билгеләнәләр. Алар аерым сүз төркеменә беркетелгән булалар һәм аның лексик составын яңа берәмлекләр белән баеталар, шулай ук аваздаш (омоним) ясагыч кушымчалар төрле сүз төркемнәрен дә ясауда катнаша ала: *авыл-даш* – исем; *тамыр-даш* (сүз) – сыйфат; *эш-чән* –сыйфат; *оек-чан* – рәвеш; *сыз-ык-ча* – исем; *татар-ча* - рәвеш һ.б.

Инде югарыда әйтелгәнчә, ясагыч кушымча сүздә бер яки берничә дә буларга мөмкин (*киер-енке-лек*). Шунысы кызык: ясагыч кушымчаларның тамырга яки нигезгә турыдан-туры ялгануы мәҗбүри түгел, алар форма үзгәртә торган кушымчалардан соңрак та килергә мөмкин: *көн-дә-лек, дус-лар-ча, әйт-ел-гән-чә* һ.б.

Телдәге сүзләрнең кайбер кушымчалары аның формасын үзгәртә, ә төп мәгънәсен яңартмый. Д.Г.Тумашева һәм башка галимнәр аларны форма ясагыч кушымчалар дип атыйлар [Тумашева 1978: 12; Хисамова 2006: 19]. Мондый кушымчалар сөйләүченең чынбарлыкка карата төрле мөнәсәбәтен белдерәләр. Академик М.З.Зәкиевнең әлеге фикеренә кушылып, без аларны мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар дип атыйбыз [Зәкиев 1972: 27].

Чыннан да, төрле сүз төркемнәрендәге мондый кушымчалар сүзнең төрле-төрле грамматик мәгънәләрен күрсәтә, бу исә укучылар өйрәнә торган тел күренешләрен чагылдырган кагыйдәләрдә дә урын алган. Дәреслекләрдә юнәлеш эш-хәлнең үтәүчегә мөнәсәбәтен (*ки-ен*), заман эш-хәлнең сөйләм

вакытына мөнәсәбәтен (*бар-ды*), тартым предметның кайсыдыр затка яки затларга мөнәсәбәтен (*әни-ем*) белдерә диелә.

Әмма бу кушымчалар арасында төрле сүз төркемнәрен һәм җөмләләрне бәйли торган кушымчалар булуы күзгә ташлана. Аларны без бәйләгечләр дип атау ягында торабыз. Әлеге кушымчаларның кулланылу даирәсе гаять киң; алар телнең грамматика бүлегендә карала торган морфологик һәм синтаксик берәмлекләрне (төрле сүз төркемнәрен һәм иярчен җөмләләрне баш җөмләләгә) бәйлиләр. Шунысын да искәртик: соңгы елларда бәйләгеч кушымчаларны барлау, аларның әһәмиятен аңлау укучыларга тебезнең төп синтаксик үзенчәлекләреннән саналган синтетик табигатенә төшенергә дә ярдәм итүе күзәтелә. Бер сүз белән әйткәндә, бу кушымчалар грамматиканы (морфология белән синтаксисны) бер бөтен итеп күзалларга да мөмкинлек тудыра. Бәйләгеч кушымчалар исемнәр белән фигыльләрдә, исемләшкән очракта башка сүз төркемнәрендә дә күзәтелә

Мөнәсәбәт белдерүче бәйләгечләрдән калган кушымчалар модальлек кушымчалары дип атала; алар сөйләүченең үзен чолгап алган дөньяга – чынбарлыкка төрлечә мөнәсәбәтен белдерә: *кыз-чык* – кечерәйтеп әйтү; *дус-кай* – иркәләп эндәшү һ.б.

Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар да аваздаш (омоним) булырга мөмкин: *китап-лар* – исемнең күплек сан формасы; *кайтты-лар* – хикәя фигыльнең III зат күплек сан формасы.

Модальлек һәм бәйләгеч кушымчаларның сүз төркемнәрендәге бүленеше түбәндәге таблицада ачыграк күренә:

| Модальлек кушымчалары | Бәйләгеч кушымчалар |
|---|---|
| Исемнәрдә:<br>иркәләү-кечерәйтү *кыз-чык;*<br>күплек сан: *шәһәр-ләр.* | Исемнәрдә:<br>килеш: *урам-га*;<br>тартым: *кул-ым.* |

| | |
|---|---|
| Сыйфатларда:<br>чагыштыру һәм кимлек дәрәҗәсе: *олы-рак,ак-сыл.* | Сыйфатларда:<br>исемләшкәндә күплек сан, килеш һәм тартым: *кызыл-лар-ы-н (җыйды).* |
| Рәвешләрдә:<br>чагыштыру дәрәҗәсе: *тиз-рәк.* | Рәвешләрдә:<br>исемләшкәндә күплек сан, килеш һәм тартым: *күп-ләр-не (күргән).* |
| Саннарда:<br>сан төркемчәләре: *җиде-нче.* | Саннарда:<br>исемләшкәндә күплек сан, килеш һәм тартым: *бишенче-ләр-не (ярышка җибәрделәр).* |
| Фигыльләрдә:<br>юклык: *кил-мә*;<br>заман: *кит-кән*;<br>юнәлеш: *ки-ен-ә*;<br>дәрәҗә: *көл-емсерә*. | Фигыльләрдә:<br>затланышлы фигыльләрдә:<br>зат-сан: *бара-м, барса-м*;<br>шарт фигыль: *укы-са;*<br>затланышсыз фигыльләрдә:<br>хәл фигыль: *укы-п;*<br>исем фигыль: *йөр-ү*. |

Әлеге кушымчалар сүз төркемнәрендә төрлечә урнашулары белән аерылып тора.

Бәйләгеч кушымчалар, гадәттә, сүз ахырында булалар (алар бәйлиләр).

Исемнәр белән фигыльләрдә модальлек кушымчалары ясагычлардан соң, аннары - сүз ахырында бәйләгечләр килә: *эшче-ләр-гә, уйла-ды-лар.* Бәйләгеч кушымча булмаганда, сүзләрне модальлек кушымчасы төгәлли: *кош-чык, кош-кай.* Модальлек кушымчасы булмаса, тамыр яки нигездән соң бәйләгеч кушымча килә: *җырла-са, кеше-гә.*

Исемнәрдә икешәр модальлек (*дус-кай-лар)* һәм бәйләгеч *(авыл-ым-ны)* булырга мөмкин. Фигыльләрдә модальлек кушымчалары шактый күп: *ки-ен-мә-де, ки-ен-дер-де, көл-емсерә-штер-гәл(ә)и.*

Бу мәкаләдә сүзләрнең морфемик төзелешенә караган кайбер үзенчәлекләр генә яктыртылды. Шулай итеп, без татар телендә сүзләрнең морфемик төзелеше кызыклы үзенчәлекләргә ия булуын күрәбез. Аларны өйрәнү һәм өйрәтү бер яктан, телебезнең төп билгесен – аның ялганмалы булуын аңларга ярдәм итсә, икенче яктан аның грамматика дип аталган зур бүлегенең үзара тыгыз бәйләнгәнгән өлешләрен – сүз ясалышы, морфология һәм синтаксисны үзләштерүдә дә таяныч була ала.

*БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЙ СПИСОК*

*Зәкиев* М.З. Татар теле морфологиясенә кереш // Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе / З.М.Вәлиуллина, К.З.Зиннәтуллина, М.Ә.Сәгыйтов. – Казан, 1972. – 206 б.

*Татар* грамматикасы. – Т. I. – М.: «ИНСАН», Казан: «ФИКЕР», 1998. – 512 б.

*Тумашева Д.Г.* Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. – Казан: КДУ нәшр., 1978. – 221 б.

*Харисова Ч.М.* Татар теле. Морфология: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2010. – 128 б.

*Хисамова Ф.М.* Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.